Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№40 (91)

12 декабрь 2013 ел



# «Кояш-кыз»!

Чын студент нинди була дисезме? Әлбәттә, ул параларны калдырмаска, яхшы укырга, белемгә омтылырга тиеш. Әмма бу гына аз. Студент кеше укудан тыш чараларда да катнашып, үзен күрсәтә белергә, нәтиҗә-табышларны башкалар белән дә бүлешеп, актив тормыш позициясен алга сөрүче кеше булырга тиеш. КФУның Яр Чаллы институты студенты Гөлнара Миңнеханова – нәкъ шундыйлардан! Аның белән якыннанрак танышыйк.

✦ Рәсемдә: Гөлнара – Яр Чаллы институты филология һәм журналистика факультетының 4 курс студенты. Параларда тырыша-тырыша белем эстәүче Гөлнараның тәнәфесләр вакытында да ял итеп утырырга вакыты юк. «Сәбәбе нидә?» дисезме? Ә сәбәбе бер: Гөлнара «УРа» радиосы ди-джее һәм ул, тәнәфестә эфирга чыгып, башка яшьтәшләренең ял вакытын файдалы һәм күңелле итү белән мәшгуль.

Дәвамы 2 биттә

## ● Вакыйгалар эзеннән

**9 ДЕКАБРЬДӘ** ректор **И.ГАФУРОВ ФУНДАМЕНТАЛЬ МЕДИЦИНА** һәм **БИОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ КОЛЛЕКТИВЫ** һәм **СТУДЕНТЛАРЫ** белән **ОЧРАШТЫ**. Университетның конкурентлылыгын арттыру программасы кысаларында, биомедицина һәм фармацевтика – приоритетлы саналган дүрт юнәлешнең берсе. Җыелышта институтны үстерү һәм алга җибәрү идеяләре белән уртаклаштылар, булган проблемаларны чишү юлларын эзләделәр.

• • • •

Шул ук көнне ректор **И.ГАФУРОВ** җитәкчелегендә **РЕКТОРАТНЫҢ** чираттагы **УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. Административ эшләр буенча проректор – аппарат җитәкчесе **А.ХАШОВ** контроль йөкләмәләрнең үтәлеше һәм атна дәвамында булачак вакыйгалар белән таныштырды. Икътисад һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН** Үсеш программасы буенча эшчәнлекнең сыйпәнәюе турында әйтте. Конкурентлылыкны арттыру программасы буенча план үтәлгән. Проректор юл карталары тәңгәллеге буенча 6 яңа структур бүлекчә оештырылачагы хакында да әйтте. Алга таба КФУның ял һәм практика базаларын оптимальләштерү мәсьәләсе кузгатылды. Кабул итү комиссиясенең җаваплы сәркатибе **С.ИОНЕНКО** булачак абитуриентлар өчен интернет-проектлар эшчәнлеге белән таныштырды. Мондый интерактив дәресләр республикабызның район мәктәпләрендә укучыларны БДИга, олимпиадаларга әзерләүне һәм КФУның төп структур бүлекчәләрен тәкъдир итүне күз уңында тота. Ачык белем алу һәм КФУда аның тормышка ашырылуы хакында Мәгариф ресурслары үсеше департаменты директоры **Г.ИВШИНА** чыгыш ясады. Аның сүзләренә караганда, КФУ бу өлкәдә төп өч юнәлештә эшли: төп мәгариф программалары буенча белем алучы КФУ студентлары, КФУ студентлары өчен сайлап алынган әзерлек квалификациясенә өстәмә белем алу мөмкинлеге һәм читтән кергән заказчылар белән эш. Ректоратта КФУ IT-лицееның яңа директоры **ТИМЕРБУЛАТ САМЕРХАНОВ** белән дә таныштырдылар.

• • • •

**9 ДЕКАБРЬ** көнне Казан университетына ТРның **СТУДЕНТЛАР ЛИГАСЫ ПРЕЗИДУМЫ ӘГЪЗАЛАРЫ КИЛДЕ**. Визит университетыбызның «Ел студенты – 2013» бәйгесенең «Ел вузы» номинациясендә катнашуына бәйле оештырылган иде. Кунакларга Физика институтының лабораторияләре, «Universmotri.ru» студентлар телевидениесе студиясе, «УНИКС» спорт һәм концерт заллары буенча тулы һәм кызыклы экскурсия оештырылды.

• • • •

**9 ДЕКАБРЬ**, Халыкара коррупция белән көрәш көнендә, КФУның **ИКЪТИСАД** һәм **ФИНАНСЛАР ИНСТИТУТЫНДА** Де Поль университеты (АКШ, Чикаго) профессоры **ДЖОН ЭЙХЕРН АЧЫК ЛЕКЦИЯ ҮТКӘРДЕ**. Лекция вакытында катнашучылар Америка компанияләрендәге алдакчылык турында Де Поль университетыннан турыдан-туры трансляцияләнгән ике фильм карау мөмкинлегенә ия булды.

• • • •

Шушы көннәрдә **А.М.БУТЛЕРОВ ИС. ХИМИЯ ИНСТИТУТЫ** үзенең **80 ЕЛЛЫГЫН БИЛГЕЛӘП ҮТТЕ**. «УНИКС»та оештырылган концертта институт укытучылары, студентлар, аспирантлар һәм институтны элегрәк тәмамлаучылар да катнашты. Бәйрәмнең беренче өлеше хатирәләр яңартуга, килгән кунаклар белән аралашуга багышланган булса, икенче өлештә студентлар үзләренең иң яхшы иҗади номерлары белән сөенделәр.

• • • •

**ОЛИМПИЯ УТЫ ЭСТАФЕТАСЫНЫҢ** Татарстан этабы **30 ДЕКАБРЬДӘ КАЗАННЫҢ ТИМЕР ЮЛ ВОКЗАЛЫННАН БАШЛАНЫП КИТӘЧӘК**. Эстафетаны КФУ ректоры И.Гафуров, РФ элемтә һәм гаммәви коммуникацияләр министры Н.Никифоров һәм Идел буе физик культура, спорт һәм туризм дәүләт академиясе ректоры Й.Якупов кабул итеп алачак.

• • • •

**10 ДЕКАБРЬДӘ** КФУда **«ЗАМАНЧА СОЦИОЛОГИК БЕЛЕМ БИРУ: ҮСЕШ ТЕНДЕНЦИЯЛӘРЕ»** темасына түгәрәк өстәл оештырылды. Чара КФУның социология кафедрасының 30 еллык юбилее уңаеннан уздырылды.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

## ● Безнең тышлык

# «Кояш-кыз»!

**Ләйсән ИСХАКОВА,**
Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

**Башы 1нче биттә.**

Яр Чаллы институтының «УРа» («Университет Радиосы») радиосы хакында күбебез ишетеп белә. Арабызда аны һәрдаим тыңлап баручылар да күптер. Радио моннан 3 ел элек филология һәм журналистика факультетында укучы актив студентлар ярдәмендә яңгырый башлады. Энтузиазмга корылып оешкан булса да, ул бүген дә эшләвен, үсүен дәвам итә. Җитәкчесе – Рузил Мингалимов. Әлеге радио студиясендә булачак журналистлар радиожурналистика өлкәсендә беренче адымнарын ясый, әкренләп тәҗрибә туплый. «УРа» радиосын онлайн режимда kpfu-chelny.ru сайтында тыңлау мөмкинлеге тудырылган.

Гөлнара исә радио дөньясы белән 1 курстан ук кызыксына. Радио аны үзенең позитивлыгы, кешеләрнең кәефен күтәрү сәләте белән җәлеп итә. 2 курста укыганда, Гөлнара, радиога татар телендә алып баручылар кирәклеген белеп, үзенең көчен сынап карарга була һәм ялгышмый. Шул көннән алып бүгенгәчә «УРа»да ул. Гөлнара сүзләренчә, беренче эфирлардан ук радиода «Татар яшьләре» тапшыруы эшли. Исеменнән күренгәнчә, биредә татар яшьләре тормышы төрле яклап яктыртыла.

Шул ук вакытта яшь алып баручылар тарафыннан республиканы һәм, гомумән, татар дөньясын борчыган актуаль мәсьәләләр дә күтәрелә.

Гөлнара радио өлкәсендәге эзләнүләрен бүген дә дәвам иттә. Радиоэфирны тагын да мавыктыргыч һәм кызыклы итү өчен нишләргә кирәклеген дә белә ул. Бу хакта: «Туры эфирга шәһәребез күләмендә танылган кешеләрне чакырып, алар белән әңгәмә корасыбыз килә. Бу теләкне әкренләп тормышка да ашыра башладык инде», – дип бүлешә студент. Гөлнара җырларга ярата икән. Буш вакытында психология китаплары уку белән дә мавыга. Хәер, бу гаҗәп тә түгел. Журналист моңлы җырчы да, кешеләр күңелендәге серле ишекләрне ачучы психолог та була белергә тиеш.

Киләчәген дә радио һәм телевидение белән бәйләп карый тиктормас Гөлнара. Чын журналист җаваплы, пунктуаль, белемле, кыю һәм үҗәт булырга тиеш, дип саный, позитив уйлар белән елмаеп, киләчәккә караучы «Кояш-кыз».

***Сүз уңаеннан!** «УРа» радиосы «Ел студенты – 2013» бәйгесенең «Студентлар матбугаты» номинациясе буенча сайлап алу турыны икенче этабына үтте. Алга таба да уңышлар телибез!*

## ● Чара

11 декабрь көнне университетыбызның «Политсковородка» дискуссион сәяси клубы мәйданында II республика халыкара форумы уздырылды.



✦ Рәсемдә: КФУ студенты Лада Румянцева чыгыш ясый

# Куркынычсызлыкта яшәячәкбез!

**Дания ФАТЫЙХОВА**

Анда талантлы яшьләребез хокук мәдәниятен арттыруга юнәлтелгән проектларын тәкъдим итте. Аның тематикасы итеп «Куркынычсызлык» юнәлеше сайланган иде.

Әлеге яшьләр форумы инде өченче ел эшләп килә һәм анда катнашучылар саны елдан-ел арта бара икән. Быел анда барлыгы 37 проект кабул ителгән. Монда республикабызның теләк белдергән һәр уку йорты һәм җәмәгать оешмалары катнашу мөмкинлегенә ия булган. Мисал өчен, КФУ иң актив вузлардан санала. Быел бездән 13 проект тәкъдим ителде һәм аларны әлеге форумда 8 кеше яклады. Оештыручылар сүзләренчә, иң популяр темалар булып, экстремизм һәм терроризмның артуына, коррупциягә каршы тору эшчәнлеген җәелдереп җибәрү тора икән.

Түгәрәк өстәл форматында булган чарада инде читтән торып үткәрелгән турда сайлап алынган 11 иң яхшы проект тәкъдим ителде. Алар юл-транспорт һәлакәтләрен киметү, терроризм һәм экстремизмны булдырмый калу, яшьләрне гадәттән тыш һәм экстремаль ситуация шартларына әзерләү, яшьләр мохитендә ксенофобия күренешенең чагылышы, коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре һәм башка темаларга багышланган иде.

Барлык катнашучылар, проектларын тәкъдим иткәндә, аның максатына, актуальлегенә, инновационлыгына басым ясадылар. Ахырдан тугыз кешедән торган комиссия, аларны бәяләп, финалга җиңүче итеп бер проектны чыгардылар һәм иң яхшы саналган өч проектны билгеләделәр. Бу проект җитәкчеләре алга таба да эшкәртмәләре белән конкурсларда катнашып, мораль һәм матди ярдәм ала алачаклар.

## ● Заман таләбе

# Түбәтәйле шведлар!

**Мария НАЛИСИНА,**
Яр Чаллы институты

Шушы көннәрдә Яр Чаллы институтының журналистика фәне укытучысы Римма Мөхәмәтҗанова Швециядә стажировкада булып кайтты.

Бу командировка IREX компаниясе булышлыгы белән уздырылган бәйгедә җиңү нигезендә гамәлгә ашырыла. Россия күләмендә оештырылган анкеталаштыру нәтиҗәләре буенча, журналистика өлкәсендә эшләүче тугыз яшь укытучы сайланып, Стокгольмга гыйлемнәрен артырырга җибәрелә. Әлеге сәяхәт Вероника Менҗун җитәкләгән консалтинг агентлыгы һәм Fojo Media Institute – журналистларның квалификациясен күтәрү институты тарафыннан оештырыла.

Визитның программасы цифрлы медиа журналистикасына багышланган мастер-класслар җыелмасыннан гыйбарәт булган. «Масс-медиа белгече Матс Витман хәзерге журналистика тенденцияләрен мисаллар ярдәмендә аңлатты. Киләчәгебез интернет кулында, шулай да медияле технологияләр артыннан куып, текстның сыйфаты турында онытырга ярамый. Швецияле журналистлар кулланган табышлар соклану хисе һәм шул инновацион табышларны үзебездә дә кабатлау теләге уята», – дип искә ала Р.Мөхәмәтҗанова. Мастер-класслардан кала, катнашучылар күп кенә эре гомуммилли басма редакцияләрендә: швед журналистикасы флагманы, Aftonbladen таблоиды һәм Swenska Dagbladent эшлекле газетасында булу бәхетенә ирешкәннәр. «Күз алдыгызга китерәсезме: таблоид, ягъни «сары» газета сайтына кереп караучылар саны 5 млн кешедән артып китә икән, һәм бу бер атналык күрсәткеч кенә!» – дип әйтә Римма, гаҗәпләнүен яшерә алмыйча.

Стажировка кысаларында Sodertorn университеты коллегалары белән очрашу да оештырылган. Биредәге журналистларның оперативлыгы һәм мобильлеге укытучыларына да кучкән. Өч сәгать аралашу дәвамында, журналистика фәнен укытуны мөгалимнәр белән дә танышырга, элемтәләр булдырырга өлгергәннәр. «Анда журналист-студентның уртача яше – 22 яшь. Бакалавр дипломын алу өчен, өч ел укырга кирәк, ә магистратура исә алай популяр түгел икән. Белгечлек буенча эш табуы бик кыен. Сүз уңаеннан, хәзер Швециядә тиражларны кыскарту һәм, шул рәвешле, журналистлар санын киметү тенденциясе бара. Швецияләләр тиздән бу хәл



Россиядә дә кабатланачагын искәрттеләр», – дип көрсенә Чаллы укытучысы.

Катнашучылар Швеция журналистлар союзына экскурсиягә барырга да җитешкәннәр. Очрашуда мәгълүмат алу юллары турында да сөйләшкәннәр. Швециядә журналист мөрәҗәгатенә 24 сәгать эчендә җавап бирергә тиешләр икән. Бүгенге көндә журналистларның 92 проценты профсоюз әгъзалары булып тора.

Швеция ягыннан оештыручыларга һәм журналистларга Римма Равилевна республикабыздан бүләкләр: ир-атларга – түбәтәйләр, хатын-кызларга – милли күлмәкле миниатюр курчаклар алып барган. Аларны әзерләүдә шәһәр мэры Васил Шәйхразиев булышлык күрсәткән. «Безнең» бүләкләр иң яхшылары һәм үзенчәлекле булган!

Туган институтына кайткач, Р.Мөхәмәтҗанова хезмәттәшләре, Чаллы журналистлары һәм студентлар өчен зур һәм эчтәлекле ачык семинар үткәрде. «Максатыбыз – хәзерге басмаларда эшләүче журналистлардан бер адымга алдарак булырлык кадрлар әзерләү. Күп нәрсә цифрлы медиа белемен үзләштерүгә бәйле», – дип әйтә Швеция тәҗрибәсе булган укытучы.

✦ **Римма Мөхәмәтҗанова** Казан университетын тәмамлаган. 2003 елдан бирле Яр Чаллы институтының гаммәви коммуникацияләр кафедрасында эшли. «МедиаПокорение» фестивален оештыру белән шөгыльләнә.

- *Швециядә сез Карлсон сурәте төшкән сувенирларны таба алмаячаксыз. Бу илдә ул антигерой булып исәпләнә, чөнки, швецияләләр фикеренчә, ул бернинди дә батырлык эшләмәгән, ә бары Малышны дөрес юлдан тайпылдыру белән шөгыльләнгән.*
- *Таныклыгы булган журналистларга барлык музейларга керү бушлай.*
- *Биредә транспортта йөрү бәясе бик кыйммәт. Трамвайда йөрү – 200 сумнан артык. Экономия ясау өчен, барлык транспортта да кулланыла торган юл карталарыннан файдаланалар.*
- *Стокгольм үзәгендә бик күп кафе һәм чәчтарашханәләр урнашкан.*

Юбиляр

# Тынгы белмәс җан!

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

БҮГЕНГЕДӘЙ АЧЫК ХӘТЕРЛИМ: УНИВЕРСИТЕТТА УКЫЙ БАШЛАВЫБЫЗНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨННӘРЕ. ӘЛЕ ЯҢА ГЫНА СТУДЕНТ ТОРМЫШЫНА КИЛЕП КЕРГӘН «САРЫ ТОМШЫКЛАР»НЫ ОЛПАТ ГАЛИМНӘРЕБЕЗ УКЫТА БАШЛАДЫ: Х.Й.МИННЕГУЛОВ, Т.Н.ГАЛИУЛЛИН, Ф.Й.ЙОСЫПОВ, М.Х.БАКИРОВ… АЛАРНЫҢ ЛЕКЦИЯЛӘРЕН БЕЗ ЙОТЛЫГЫП ТЫҢЛЫЙ ИДЕК. НӘКЪ МЕНӘ АЛАРНЫҢ ДӘРЕСЛӘРЕННӘН СОҢ БЕЗ ҮЗЕБЕЗНЕҢ НИНДИ ЗУР БӘХЕТКӘ ИРЕШКӘНЕБЕЗНЕ АНЫК АҢЛЫЙ БАШЛАДЫК..



Әминде күптән түгел шушы галимнәребезнең берсе үзенең күркәм юбилеен билгеләп үтте. 6 декабрьдә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты бинасында профессор, филология фәннәре докторы Марсель Хәернас улы Бакировның 80 яшьлек юбилей кичәсе узды. Марсель абыйны котларга институтыбыз директоры Р.Р.Җамалетдинов, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М.Миңнуллин, Язучылар союзы әгъзалары Р.Аймәт һәм Г.Морат, «Чын мирас» журналының баш мөхәррире И.М.Ибраһимов, юбилярның хезмәттәшләре, студентлары, аны хөрмәт иткән һәм яраткан барлык дуслары җыелган иде. Кичәне профессор, филология фәннәре докторы Фоат абый Галимуллин алып барды.

Укытучыбызны бары тик шат, шактый авыр булган фольклор дәресләрен җиңел генә аңлата белгән, гаять киң күңелле кеше буларак беләбез. Шуңа һич кенә дә аны катлаулы тормыш юлы үткән дип, уйлап та карамый идек. Ә бит аның балачагы бик авыр елларга туры килгән. Марсель абыйның әтисе – Хәернас абый репрессия корбаны булган. Әнкәсе – Фатыйма апа балаларын белән яшьли ялгыз кала. Әмма, шуңа да карамастан, ул аларны тәрбияләп үстерә, кеше итә.

> Һәрвакыт эзләнү юлында, һәрвакыт китапханәдә - ул белемне бөртекләп җыя, күп укый, белгәннәре белән генә чикләнеп калмый. «Ничә карама, Марсель китапханәдә каталкага тотырып китап алган була иде. Ул да булмый, аларын инде укып бетергән, яңаларын алырга китеп бара икән», – дип, елмаеп, коллегасының тырышлыгы турында чын-чынлап сокланып искә алды.
>
> *Т.Н.Галиуллин*

Әдәбиятка, телгә һәм сәнгатькә гашыйк булган Марсель абый 1951 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Атаклы галимнәрнең лекцияләрен тыңлап, бүлектә чыккан «Әдәби сүз» газетасының эшчәнлегендә актив катнаша. Укуын тәмамлагач, монда җыйган тәҗрибә һәм белем аны Уфа шәһәрендә басылып килгән «Кызыл таң» газетасы редакциясенә алып килә. Шушы елларда ул булачак тормыш иптәше Кифая ханым белән дә таныша. Бервакытны Уфага лекция укырга Хатыйп Госман килә. Башкортстанда үзенең шәкертен очратып, ул Марсель абыйны үзенә аспирантурага укырга чакыра. Гаилә корып өлгергән булачак галим, тәвәккәлләп, янә Казанга китә. Марсель абый сүзләренчә, ул стипендиясенең яртысын Уфада торып калган гаиләсенә җибәргән, ә үзе ничек бар, шулай итеп көн күргән, әмма белем алу теләге аңарда моңа карап һич кенә дә кимемәгән. Укуын тәмамлап, университетта укыта башлагач кына, ул гаиләсен Казанга алып килә. Үзенең кандидатлык диссертациясен М.Бакиров төрки һәм татар шигыренең әчке ритмик-интонацион хасиятләрен һәм кануннарын эксперименталь юл белән тикшерүгә багышлый. Яшь галимнең бу диссертациясен кандидатлык эшеннән күпкә югарырак дип бәялиләр һәм аны докторлык диссертациясе итеп кабул итәргә телиләр. Әмма М.Бакиров киләчәктә докторлык диссертациясен дә язу теләген белдерә. Шулай итеп, 1972 елда фәнгә шактый перспективалы яшь галим килә.

Шигърияткә гашыйк булган укытучыбыз үз эшчәнлеген тәфсилле күзаллый. Ул халык иҗатын ныклап өйрәнә. Тикшеренүләрен төрки-татар поэзиясе тирәсендә генә түгел, ә фольклор буенча да алып бара башлый. Әлеге тикшеренү-эзләнүләрнең нәтиҗәсе буларак, гаҗәеп саллы хезмәт – «Шигърият бишеге. Гомумтөрки поэзиянең яралуы һәм иң борынгы формалары» дигән монография басыла. Марсель абый 1999 елда, шушы монографиягә нигезләнеп, докторлык диссертациясен яклый. Талантлы галимебез тюрколог, әдәбиятчы гына түгел, тарихчы да. Чөнки нәкъ ул, беренчеләрдән булып, борынгы төркиләрдә сүз сәнгатендә матур сөйләү – ораторлык сәнгатенең булганлыгын ача, Орхон язмаларының да шул ук традициягә нигезләнгәнлеген исбатлый.

Марсель абыйны еш кына китапханәдә очратырга мөмкин. Үз үрнәге белән ул безгә, үзенең студентларына, белемнең беркайчан да артык булмавын һәм тырышкан кеше генә фән дигән иксез-чиксез дәрьяның асылташларын табуга ирешә алачагын исбатлый.

Яраткан укытучыбызга киләчәктә ныклы сәламәтлек, эшендә уңышлар, теләкләренең тормышка ашуын телибез һәм аңа зур рәхмәтләребезне җиткерәбез!

Аталар сүзе - акылның үзе

# Каз канаты кат-кат була…

**Гөлчәчәк ХӘСНУЛЛИНА,** Филология
һәм мәдәниятара багланышлар институты

АВЫЛ ДИГӘЧ, КҮҢЕЛЛӘРНЕҢ КҮЗ АЛДЫНА ҮЗ ТУГАН ЯКЛАРЫ, ЯЛАНАЯК УЙНАП ҮСКӘН ЧИРӘМНӘРЕ, ЧЕЛТЕР ЧИШМӘЛӘРЕ БЕЛӘН ХӘТЕРДӘ САКЛАНГАН ТУГАН АВЫЛЫ КИЛЕП БАСА. МИНЕМ ӨЧЕН ТУГАН АВЫЛ – УЛ ЯШЕЛ ЧИРӘМ, ШУЛ ЧИРӘМГӘ ГӘРӘБӘДӘЙ СИБЕЛГӘН НӘНИ «КОЯШЛАР» – КАЗ БӘБКӘЛӘРЕ. ШУЛ БӘБКӘЛӘРНЕ ТИЛГӘН АЛМАСЫН ДИП, АЛАР ЯНЫННАН КИТМИЧӘ, ҖӘЙГЕ ЭССЕДӘ УРАМДА, ЧИРӘМДӘ УТЫРУЛАР….





Тик хәзер авылларда каз асраучылар бермә-бер кимеде. Ә шулай да каз асрау – кызык шөгыль, кечкенәдән үзең үстергән, тәрбияләгән каз бәбкәләрен көзләр житкәч, үзең санауга ни җитә?

Көзләрнең соңгы атнасы җитеп, җиргә инде карлар төшә башлагач үткәрергә ярата халкым каз өмәсен. Ул көнне, таң ату белән, йорт хуҗасы – ир кеше – казларны чала, ул вакытта хатын-кызлар көндәлек эшләрен тәмамлап, казан астына, мунча миченә ягып куя. Чалынган казларны я мунчада, я, җылы көн булса, тышта гына йолкыйлар.

Каз йолку процессын да төрле якта төрлечә башкаралар: кемдер кайнап торган суга казны бөтен килеш салып ала да йолкый башлый, ә соңыннан исә юеш мамыкларны җыеп киптерә. Кемдер юеш чүпрәк белән казны төреп, үтүк белән шул чүпрәк өстеннән бастыра.

Каз йолку шактый вакытны алса да, күмәкләшеп эшләгәндә, ул сизелми үтеп китә. Казларның тәнендә вак кына йоннар булса, әбиләр аны «бала йонлы» каз булган диләр. Казның андый чагына туры килмәс өчен, аларны айның билгеле бер көнендә генә суярга кирәк.

Һәр йолкынган казны тышка, ап-ак кар өстенә чыгарып бару мәслихәт, чөнки, эчен чистартканда, эрегән майны алу авыр. Эче алынган казларны калган өмәчеләр пешекли тора. Бу канат астында, аякларында, муеннарында калган йоннарны йолку өчен кирәк. Аннары казларны су буена алып төшеп чайкыйлар. Казларны күтәргән апалар алдыннан балалар каз мамыкларын юлга чәчеп төшәргә тиеш, бу икенче елга да казлар мул булсын өчен эшләнә.

Казларны су буеннан алып менгән өмәчеләрне өйдә чәй көтә, бу вакытта инде өстәлгә каз коймагы куела. Өмәчеләр чәйдән соң өйгә таралыша. Бу көнне кичен яшьләр аулак өй үткәрә. Әлеге аулак өйләрдә каз өмәсе, аңа бәйле булган ырымнар турында сөйләгәннәр. Кызганыч, бүген исә каз өмәсе өлешчә генә яшәп килсә дә, аулак өйләр ясап, җырлап утырулар юк инде. Каз йолкыганда, өмәчеләрнең төрле мәзәк хәлләр сөйләп, җырлашып утырулары саклансa да, яшьләр бу традицияләрне белми диярлек.

Һәр ел саен каз суеп, туганнар белән каз өмәсе үткәргәндә, минем күңелдә менә шул мизгелләр яңара, уйландыра башлый. Дәү әнием сөйләгән каз өмәләрен, аулак өй кичләрен үткәрәсем килә башлый. Ләкин андый күмәк эшләрне бер кеше генә башкарып чыга алмый, башкаларның да актив булуы, теләге кирәк. Шуңа күрә, әйдәгез, авылларда, урамнарда татар халык җырлары яңгырасын, каз өмәләре үтсен, күңелле итеп, бергә-бергә ял итик.

## Каз өмәсе ырымнары:

- *Каз бәбкәләре күп чыксын өчен, кыр казлары кайтканда, аяк астыннан салам яки чүп алып, каз астына салырга кирәк.*
- *Киләсе елга шуай тезелеп кайта торган бәбкәләр чыксын дип, сыдырган каурыйларны сукмакка чәчәләр.*
- *Казның сул канатын кешегә бирергә ярый, уң канатын бирсәң, кул китә (бәбкәләр аз чыга башлый).*
- *Каз башын, каз тәпиен кызларга тараталар.*

• Әдәби сәйләннәр

# Җил һәм Суык яки аңлашу

Айгөл АБДРАХМАНОВА

*Башы алдагы санда.*

Әллә кайчаннан бирле таныш инде бу хис белән Айсылу. Мәхәббәт яшькә карамый бит ул.

– Гафу ит, Айсылу, озак көттердем, ахрысы. – Айнурның тыныч, ләкин шул ук вакытта көчле, яңгыравык тавышы тирә-юньдә урнашкан тынлыкны бозды, сәер уйларны еракка куып җибәрде.



Каршында басып торучы, әкияттәге баһадирдай озын буйлы, төз гәүдәле егет Айсылуның хис-тойгыларын тагын бер кат пыран-заран китерде. Кызның тез буыннары калтырый башлады, күз аллары караңгыланды, каушаудан, Айсылу исәнләшергә дә онытты. «Тагын башына кимәгән, салкын тидереп бетерә инде», – дип, кечкенә баласы турында кайгырткан ана шикелле борчылды Айсылу. Ул үзенең дусты, юк, дусты түгел, яраткан кешесе турында гомере буе кайгыртырга, үзенең кечкенә җилкәләре белән Айнурны бәла-казалардан сакларга әзер иде... «Тик, ни кызганыч, бу теләк уртак түгел. Айнур миңа сыйныфташына карган кебек кенә карый шул», – дип уйлады Айсылу.

Айнур исә бу вакытта үзенең хисләрен яшерергә тырышты. Айсылуның күзләрендәге нур, кайнар мәхәббәт ялкыны аның йөрәген пешереп-пешереп алды. Юл буе әзерләп килгән сүзләре буталды, онытылды. Айнур, карурманда адашкандай, хисләр ташкынында адашты. Үзен кулга алырга тырышты һәм, ниһаять, бөтен хисләрен җиңеп, йөзенә битарафлык төсмере чыгарды.

– Айсылу, ни... мин...

«Кара инде, нәрсә булды соң сиңа, Айнур? Кирәкмәгәндә сүзләрең белән таш ярасың, ә кирәктә бер җөмлә төзеп әйтә алмыйсың», – дип тиргәде егет үзен.

«Нәрсә әйтергә телисең соң син, Айнур? Ник болай каушыйсың? Ах, әллә синнән бу сүзләрне ишетергә насыйп булыр микән? Әллә син дә мине яратасыңмы?» – дип уйлады Айсылу. Бу уйдан кызның йөзенә алсулык йөгерде, күз кабаклары авырайды, күзләренә яшь килде.

– Мин... мин сине... ни...

– Кирәкми, Айнур. Кирәкми, берни дә әйтергә кирәкми. Мин барысын да аңладым. Синең күзләрең әле генә миңа барысын да сөйләп бирделәр...

– Гафу ит мине барысы өчен дә, – диде егет һәм курткасының кесәсеннән кәгазьдән ясалган кып-кызыл роза чәчәге чыгарды.

Гашыйк йөрәкләр тын гына аңлаштылар, сүзсез генә аралаштылар. Айсылу һәм Айнур янәшәдә генә йөргән Җил белән Суыкны да сизмәделәр. Алар өчен тирә-юньдә берәү дә юк, бу мизгелдә алар тик икәү генә иде...

– Күрдеңме, Суык?! Мин бу хәлнең шулай тәмамланасын Айсылуга әллә кайчан ук әйткән идем, – дип куанды Җил.

– Син һәрвакыт дөрес сөйлисең, – дип куәтләде дустын Суык.

• Яшьлек-яңарыш

5 декабрь көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге каршында эшләп килгән «Әллүки» әдәби иҗат түгәрәге Бөтенроссия «Шигъри сабантуй» фестивале уздырды.

# «Шигъри сабантуй» батырлары

Халисә ШИРМӘН,
«Әллүки» түгәрәгенең кураторы

Әлеге чарада Башкортстан, Пенза өлкәсе, Удмуртия һәм Татарстанның төрле районнарыннан 117 студент һәм мәктәп укучылары үз шигырьләре белән катнашты, бәйрәм көнне шуларның 83е тамаша залына килгән иде. Катнашучылар өчен ике сәгать дәвамында мастер-класслар эшләде: «Татар балы» җәмгыятеннән Энҗе Ибраһимова һәм «Синең көчең» газетасы баш мөхәррире Алмаз Мансуров яшьләр белән татар тормышы, шигырь сәнгате турында кызыклы әңгәмә оештырдылар, актив катнашучылар китаплар белән бүләкләнде. «Шигъри сабантуй» алдыннан мәртәбәле жюри бердәм тавыш белән ике номинациядә җиңүчеләрне билгеләде. Мәктәп укучылары арасында үткәрелә торган «Яшь батыр» номинациясендә өченче урынны өч укучы бүлеште: Яңа Савин районы 177 гомуми урта белем бирү мәктәбенең 10 сыйныф укучысы **Якупова Камилла**; А.М.Булатов исемендәге Кукмара күппрофильле лицееның 9 сыйныф укучысы **Гиззатуллина Әдилә** һәм Казан шәһәре Киров районы МАОУ «4 гимназия-интернат»ның 11 сыйныф укучысы **Фатыхова Гүзәл**. Икенче урынга ике укучының шигырьләре лаеклы дип табылды: Актаныш Сәләтле балалар өчен гуманитар гимназия-интернатның 10 сыйныф укучысы **Исламова Ләйлә** һәм Саба муниципаль районы Ш.З.Зиннуров исемендәге Сатыш урта гомуми белем бирү мәктәбе укучысы **Дәүләтова Альмира**. Беренчелекне исә Кама Тамагы районы, Олы Кариле урта мәктәбенең, 11 сыйныф укучысы **Хәбибрахманова Айзирә** алды.

Студентлар арасында уздырыла торган «Сабантуй батыры» номинациясендә өченче урынны КФУның Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты студенты **Нургатина Алсу** һәм М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогия университетының башкорт филологиясе факультеты студенты **Кансурина Әлфидә** бүлеште. Икенче урынга уку йортыбызның Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү институтының 2 курс студенты **Байназаров Эльнар** һәм Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге 3 курс студенты **Хәбибуллина Ләйлә** чыкты. «Сабантуй батыры» исемен Казан кооперация институты студенты **Нәгыймуллина Дания** яулады.

## Татар исән,диләр

Айзирә ХӘБИБРАХМАНОВА

*Татарлыгың кайда, татарым.*
(Р. Мөхәммәтшин)

*«Татар һаман исән әле, – диләр,*
*Үлмәс милләт, яшәр мәңгегә».*
*Тик кыйблага карап баскан халкым*
*Бер-береннән йөзен чөерә.*

*Татар исән?! Мескен инсан сыман,*
*Үз чатына поскан татарым.*
*Я, әйтегез, кайда көчле рухлы,*
*Мәңге сынмас минем Ватаным?*

*Татар теле, Ана теле, дидек,*
*Кемнәр сата икән Ананы?*
*Юк берәү дә көрәшүче бүген,*
*Төзәтерлек көч юк хатаны.*

*Татар һаман исән әле, диләр...*
*Ә кояш бит төшкә авышкан.*
*Туган телем, газиз татар телем*
*Өч тиенгә күптән алмашкан.*

*Кайтавазлар тынган, күңелләр туң.*
*Бу сыктаулар – безнең җимештер.*
*Әнә халкым түбәнгә юл алды.*
*Ә татар бит исән, имештер...*

## Тынлыкта

Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА

*Юк, дәшмә!*
*Бозма син тынлыкны,*
*Ул синең бүләгең.*
*Кайчандыр*
*Шул тынлык эчендә*
*калдырдың.*
*Бәлки, мин урынсыз качамдыр*
*Кояштан,*
*Үземнән*
*Тынлыкка.*
*Хәтерем гөрселдәп аумады*
*Зәмһәрир кышларда туңып та.*
*Исемең йөрәктән яу алды.*
*Дәшәргә уңайсыз шуңадыр.*
*Гадәткә әйләнде –*
*Яшьләрем*
*Һәркөнне битемнән шуадыр.*
*Тынлыгым урлама –*
*Бүләгең*
*Тырналган йөрәктән кубарма.*
*Барысы да яхшы!*
*Аз гына*
*Иреннәр чатнаган...*
*Су бармы?*



• Студент колагына

# Лекция язаргамы?

Киңәшләрне **Алисә ӘХӘТОВА** бирә, Гаммәви коммуникация һәм социаль фәннәр институты

XXI гасыр – мәгълүмати технологияләр һәм инновацияләр чоры. Үсеп килүче яшь буын яңа техника һәм технологияләр белән кызыксына, ә кайбер укытучылар үзләренең ныклап урнашкан, гадәтләнгән алымнарын үзгәртергә ашыкмыйлар. Шуңа күрә күп кенә уку йортларында укытучылар студентлардан лекция яздыруны дәвам итәләр. Ә күктәге кояш йөзен күбрәк ача барган саен, ул эшне эшләү ялыктыра башлый.



- Лекция язуның кайбер өстенлекләре бар. Күпчелек укытучылар студентның лекцияне язу-язмавына игътибар итә. Кайберләре дәрес вакытында аудитория буйлап йөри һәм күзәтә. Беренче курс студентлары: «Ул мине барыбер белми һәм лекция язмавымны хәтерендә калдырмас», – дип уйласалар да, укытучы курс ахырында, югары курсларда бар кешене дә таныячак, хәтта кайберләренең исемен, фамилияләрен дә беләчәк. Шуна күрә зачет, имтиханга кадәр сезнең турыда билгеле бер фикер туплаячак.
- Тагын бер унай ягы – язган вакытта материалның эчтәлеге турында уйланырга туры килә, ул күбрәк истә кала. Барысы булмаса да, кайбер мәгълүмат сакланып калачак.
- Кайвакыт лекция язып барган дәфтәр белән зачет яки имтиханга керү мөмкинлеге була. Кайбер укытучылар имтиханда бу дәфтәрне күрсәтүне мәҗбүри итеп тә куялар.
- Яхшы язылган лекция автомат зачет алу мөмкинлеген арттыра. Язмалар пөхтә, чиста, матур, берничә төсле каләм кулланып язылган, кирәклерәк мәгълүматлар аерып күрсәтелгән булырга тиеш.
- Барлык лекцияләр дә дәфтәрдә булса, имтиханнар алдыннан китап актарып утырмаячаксың. Чөнки бөтен материал да язылган.
- Кайбер укытучылар имтихан вакытында лекция дәфтәрен кулланырга рөхсәт бирергә мөмкин. Тик бер шарт белән: ул укучының үз кулы белән язылган булырга тиеш.
- Лекцияләр дәфтәрен имтихан вактында «бомба» рәвешендә кулланырга була. Ләкин һәр лекция яна биттән башланырга тиеш.
- Бу дәфтәрләр соңгы курста, ягъни диплом яклар алдыннан, имтиханнар биргәндә кирәк булачак. Дәүләт имтиханындагы сораулар арасына беренче курста укылганнар да кертелергә мөмкин. Ә ничә ел үткәннән соң, аларны кайдан табарга? Әлбәттә, дәфтәрләрен саклаган студентларга баш ватасы юк. Ә вакытында лекция язарга иренеп утырганнарга бераз йөгерергә, эзләнергә һәм түбән курс укучыларының язуларын танып азапланырга туры киләчәк.

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълумати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.